ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САЛАУССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
САЛАВЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
16 декабрь 2019ел

**КАРАР**
№36

**Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентларны раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, 2010 елның 2 ноябрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 нче карарына, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр” 2019 ел 19 апрель 167 карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамәләр һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 кушымта).

1.2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының бу хакта мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамәне урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Салавыч авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Сибагатуллин